**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

**№ 98** **«24» сентябрь 2018 ел**

**Җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясы нигезендә», Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә түбәндәге мәсьәләләр буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:
«2019 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча түбәндә язылган эшләрне башкару өчен көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300,0 сум үзара салым кертү белән килешәсезме:

*** Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**
*** Җирлек территориясен төзекләндерү;**
*** Көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чар җыюны һәм чыгаруны оештыру.**

ӘЙЕ ЮК»

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:
- ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, 2 нче Октябрь урамы, 50нче йорт, мәдәният йорты бинасы;
- ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, Октябрь урамы 65нче йорт, авыл җирлеге бинасы, шулай ук “Идел таннары” газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга»

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Кама Тамагы муниципаль районы

Тәмте авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Тәмте
авыл җирлеге Советы Рәисе И.А. Зиновьев